Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

2020 елның 7 августы № 22

**Эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында**

Эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2-1 статьясындагы 5 пункты нигезендә, Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру Тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кукмара муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе: Р.Ф.Маликов

Кукмара муниципаль районы Олыяз
авыл җирлеге башкарма комитетының
2020 елның 07 августындагы 22 номерлы
карарына кушымта

Эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру Тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитетында (алга таба – авыл җирлеге) эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын оештыру һәм үткәрүгә карата таләпләрне билгели:

1.2. Әлеге Тәртипнең максаты:

- Җирлек бюджеты акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны бәяләү;

- бухгалтерлык хисабы һәм хисаплылыкның дөреслеген раслау, шул исәптән муниципаль программаларны гамәлгә ашыру турында;

- бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив актларны үтәүне бәяләү.

1.3. Эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудиты җирлекнең вазыйфаи затлары тарафыннан, бюджет акчаларын баш бүлүчеләргә (алучыларга) һәм аларга караган җирлек бюджеты акчаларын алучыларга карата, җирлек бюджеты керемнәре администраторларына, җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары администраторларына карата башкарыла.

2. Эчке муниципаль финанс аудиты объектлары

2.1. Эчке финанс аудитының предметы булып җирлек башкарма комитеты тарафыннан бюджет акчаларын баш бүлүче (алучы), бюджет керемнәренең баш администраторы, җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы (алга таба – аудит объектлары) буларак башкарылган финанс һәм хуҗалык операцияләре җыелмасы, шулай ук эчке финанс контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру тора.

3. Эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын оештыру

3.1. Эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын тормышка ашырганда тикшерүләр, ревизияләр, обследованиеләр (алга таба – контроль чаралар) үткәрелә:

- аерым финанс һәм хуҗалык операцияләренең законлылыгын документаль һәм фактта өйрәнү буенча, бюджет (бухгалтерлык) исәбен алу һәм бюджет (бухгалтерия) хисаплылыгының дөреслеге буенча, контроль объектының билгеле бер чордагы эшчәнлегенә карата бухгалтерлык (финанс) хисабына контроль гамәлләр башкару аңлашыла торган тикшерү;

- контроль объекты эшчәнлеген кылынган финанс һәм хуҗалык операцияләренең барлык җыелмасының законлылыгын документаль һәм фактта өйрәнү, бюджет хисаплылыгында, бухгалтер (финанс) хисаплылыгында аларны чагылдыруның чынлыгы һәм дөреслеге буенча контроль гамәлләр үткәрүдә чагыла торган комплекслы тикшерүне аңлата торган ревизия;

- контроль объектының билгеле бер эшчәнлек өлкәсе торышына анализ һәм бәя бирү күздә тотыла торган обследование.

Тикшерү, ревизия нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, ә обследование нәтиҗәләре бәяләмә белән рәсмиләштерелә.

3.2. Эчке муниципаль финанс контролен (аудитын) гамәлгә ашыру буенча контроль чаралар расланган план нигезендә үткәрелә.

3.3. Эчке муниципаль финанс тикшерүе (аудит) чараларын планлаштыру элегрәк үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләрен исәпкә алып, беренчел документларны,

бухгалтерлык исәбе регистрларын, норматив документларны, планлы, хисап мәгълүматларын, бюджет законнарын, бюджет акчаларын максатсыз һәм (яки) нәтиҗәсез куллануны, бухгалтерлык (бюджет) исәбенең һәм хисаплылыкның дөрес булмавы турында фаразларга мөмкинлек бирә торган бүтән төр мәгълүматларны өйрәнү юлы белән, шулай ук, елына бер тапкырдан да ким булмаган вакыт эчендә контрольлекне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3.4. Кирәк булганда, планнан тыш контроль чаралар үткәрелергә мөмкин.

3.5. Еллык тикшерү планы Җирлек башлыгы тарафыннан раслана.

3.6. Планнан тыш тикшерүләр Җирлек башлыгы йөкләмәсе буенча үткәрелә.

3.7. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр җирлек башлыгы чыгарган күрсәтмә нигезендә үткәрелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: контроль объектының исеме, тикшерелә торган чор, тикшерү темасы һәм нигезе, эш төркеме составы һәм тикшерү чарасын үткәрү вакытлары.

3.8. Контроль чарасын үткәрү турында контроль объектына язмача хәбәрнамә белән хәбәр ителә.

3.9. Планнан тыш тикшерү чаралары контроль объектына язмача хәбәрнамә ителмичә үткәрелә.

3.10. Эчке финанс контролен оештыруны җайга сала торган нормалар эчке финанс аудитын оештыруга да кагыла.

4. Эчке финанс контролен үткәрү

4.1. Җирлек башкарма комитеты:

а) Җирлек бюджеты акчаларын баш бүлүче буларак, түбәндәгеләр буенча эчке финанс контролен гамәлгә ашыра:

- чыгымнар буенча җирле бюджетны төзү һәм үтәү, баш идарәче һәм аңа ведомство буйсынуындагы җирле бюджет акчаларын алучылар тарафыннан бюджет хисаплылыгын төзү һәм бюджет исәбен алып бару буенча эчке стандартларны һәм процедураларны үтәү;

- бюджет акчаларын куллануның экономиялелеген һәм нәтиҗәлелеген арттыру чараларын әзерләү һәм оештыру;

б) җирлек бюджеты керемнәренең баш администраторы буларак, чыгымнар буенча бюджетны төзү һәм үтәү, баш идарәче тарафыннан бюджет хисаплылыгын төзү һәм бюджет исәбен алып бару буенча эчке стандартларны һәм процедураларны үтәүгә юнәлдерелгән эчке финанс контролен гамәлгә ашыра;

в) җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы буларак, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджетны төзү һәм үтәү, әлеге җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы тарафыннан бюджет хисаплылыгын төзү һәм бюджет исәбен алып бару буенча эчке стандартларны һәм процедураларны үтәүгә юнәлдерелгән эчке финанс контролен гамәлгә ашыра.

4.2. Тикшерү чарасын үткәрүгә керешеп, тикшерү объектына тикшерү чарасын үткәрү турында күрсәтмә күчермәсе тапшырыла.

4.3. Эшче төркем җитәкчесе һәм әгъзалары хокуклы:

- контроль объектының территориясендә, административ биналарында һәм хезмәт биналарында булуырга;

- үзенең оештыру-техник чараларын, шул исәптән компьютерлар, ноутбуклар, калькуляторлар, телефоннар кертергә, чыгарырга һәм алардан файдаланырга;

- контроль чаралар максатларына ирешү өчен, барлык кирәкле документларны алырга (белешмәләр, язма аңлатмалар һәм башка документлар);

- документларның күчермәләрен кәгазьдә дә, электрон рәвештә дә алырга һәм контроль чара материалларына җәлеп итәргә;

- автоматлаштырылган системаларның мәгълүмати ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген алырга;

- тикшерелүче мәсьәләләрнең асылы буенча телдән аңлатмалар алырга.

4.4. Контроль чара барышында түбәндәгеләр буенча контроль гамәлләр үткәрелә:

- исәп регистрларындагы язмаларны беренчел исәп документлары белән чагыштыру юлы белән бюджет (бухгалтер) исәбендә һәм бюджет (бухгалтер) хисабында кылынган финанс һәм хуҗалык операцияләренең тулы, үз вакытында һәм дөрес чагылдырылуы;

- җирлекнең муниципаль милкендәге товар-матди кыйммәтләрнең, акчалата чараларның һәм кыйммәтле кәгазьләрнең фактта булуы, сакланышы һәм дөреслеге, исәп-хисапларның, куелган товарлар күләменең, башкарылган эшләрнең һәм күрсәтелгән хезмәтләрнең, чыгымнарны һәм финанс нәтиҗәләрен формалаштыру буенча операцияләрнең һәм финанс нәтиҗәләренең дөреслеге;

- контроль объектының бюджет (бухгалтер) исәбен һәм бюджет (бухгалтер) хисаплылыгын куюы һәм торышы;

- матди кыйммәтләр һәм акчалар хәрәкәтенә карата, чыгымнарны формалаштыруның дөреслегенә, керемнең тулылыгына, акчаның һәм матди кыйммәтләрнең сакланышына һәм факттагы булуына, башкарылган эшләрнең һәм күрсәтелгән хезмәтләрнең дөреслегенә карата агымдагы контрольнең булуы һәм торышы;

- расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә бюджет акчаларын файдалануның нәтиҗәлелеге, адреслылыгы һәм максатчан характеры;

- максатчан билгеләнешле бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар, шулай ук башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләре алучыларның аларны биргәндә билгеләнгән шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәве;

- бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне планлаштыру (прогнозлау);

- тикшерү объекты карамагына бүлеп бирелгән бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын түләү өчен билгеләнгән ассигнованиеләрне куллануның адреслы һәм максатчан характеры;

- бюджет сметаларының үтәлеше, агымдагы эшчәнлек, бюджет хисаплылыгы белән бәйле чыгымнарның нигезле булуы;

- хокук бозуларны бетерү, матди зыянны каплау, алдагы тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча гаепле затларны җаваплылыкка тарту буенча контроль (аудит) объекты тарафыннан чаралар күрү.

Контроль чаралар барышында шулай ук персоналның эш вакытында эш урыннарында булуын һәм уку планының дәресләрне үткәрү графигы белән тәңгәл килүен тикшереп тору гамәлгә ашырыла.

4.5. Контроль чаралар расланган план нигезендә үткәрелә.

4.6. Тикшерү һәм ревизия нәтиҗәләре акт белән, обследованиенеке — бәяләмә белән рәсмиләштерелә.

4.7. Акт кереш, тасвирлау һәм йомгаклау өлешләреннән тора.

4.8. Тикшерү яки ревизия акты ике нөсхәдә төзелә һәм тикшерү чарасын гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар тарафыннан имзалана.

4.9. Тикшерү яки ревизия актының бер нөсхәсе контроль оешмасы җитәкчесенең танышу турындагы билгесе белән комиссия рәисендә саклана, икенчесе, законнар нигезендә карарлар кабул итү һәм карау өчен, администрация башлыгына җибәрелә.

4.10. Контроль объектлары (аларның вазыйфаи затлары) хокуклы:

а) күчмә тикшерүләр (ревизияләр, обследованиеләр) кысаларында үткәрелә торган контроль объекты эшчәнлеген фактта өйрәнү (тикшерү, инвентаризацияләү, күзәтү, яңадан исәпләү, экспертиза, исследование, контроль үлчәү (үлчәү) буенча контроль гамәлләр үткәргәндә катнашырга, темага кагылышлы һәм контроль чара уздыру барышында өйрәнелергә тиешле төп мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

б) Россия Федерациясе законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә контроль органы һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирергә;

в) тикшерү, ревизия (тикшерү) нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән акт (бәяләмә) буенча каршылыкны тикшерү органына язма рәвештә тапшырырга.

4.11. Контроль объектлары (аларның вазыйфаи затлары) бурычлы:

а) контроль органы вазыйфаи затларының законлы таләпләрен үтәргә;

б) контрольлек итү органының вазыйфаи затларына контроль чаралар үткәрү өчен кирәкле язма яки телдән аңлатмалар бирергә;

в) контроль чаралар үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны үз вакытында һәм тулы күләмдә соратулары буенча контроль органының вазыйфаи затларына тапшырырга;

г) күчмә тикшерү (ревизия, обследование) үткәрүдә катнашучы вазыйфаи затларга контроль объектлары биләгән биналарга һәм территорияләргә, шулай ук экспертиза һәм тикшеренүләр объектларына керергә рөхсәт күрсәтергә;

д) контроль чаралар үткәрүдә катнашучы вазыйфаи затларны, контроль чаралар үткәрү өчен кирәкле бүлмәләр һәм оештыру техникасы белән тәэмин итәргә;

е) контроль чаралар үткәрүдә катнашучы вазыйфаи затларга фото-һәм видеога төшерү, әлеге вазыйфаи затларның гамәлләренең тавыш – һәм видеоязмалар алып барылуы турында хәбәр итәргә;

ж) булган контроль объекты хуҗасы яки операторы булган контроль чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле, хуҗасы яки операторы контроль объекты булган мәгълүмат системаларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә;

з) тикшерү чарасын үткәрүгә комачаулауга юнәлдерелгән гамәлләр (гамәл кылмау) башкармаска

4.12. Ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чараларның барышын Авыл җирлеге башлыгы контрольдә тота.

5. Эчке финанс аудитын үткәрү

1. Эчке финанс аудиты түбәндәгеләрне формалаштыру һәм бюджет акчаларының баш администраторы җитәкчесенә, бюджет акчаларын бүлүченең җитәкчесенә, бюджет акчаларын алучының җитәкчесенә, бюджет керемнәре администраторы җитәкчесенә, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторы җитәкчесенә бирү буенча эшчәнлек булып тора:

1) бюджет акчаларын бүлүченең, бюджет акчаларын алучының, бюджет керемнәре администраторының, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторының (алга таба – бюджет акчалары администраторы), бюджет акчаларының баш администраторының бюджет вәкаләтләрен үтәвен бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат, шул исәптән бюджет хисаплылыгының дөреслеге турында бәяләмә;

2) финанс менеджментының сыйфатын күтәрү, шул исәптән бюджет акчаларын кулލануның нәтиҗәлелеген һәм экономиялелеген арттыру турында тәкъдимнәр;

3) финанс менеджментының сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән карарларны үтәү нәтиҗәләре турында бәяләмә.

2. Эчке финанс аудиты түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

1) бюджет акчалары баш администраторының, бюджет акчалары администраторының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актларда билгеләнгән үз бюджет вәкаләтләрен үтәүгә карата таләпләрне үтәү максатларында гамәлгә ашырыла торган эчке процессының ышанычлылыгын бәяләү(алга таба – эчке финанс контроле) һәм эчке финанс контролен оештыру турында тәкъдимнәр әзерләү;

2) бюджет хисаплылыгының дөреслеген һәм бюджет исәбен алып бару тәртибенең бюджет исәбенең бердәм методологиясенә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы

тарафыннан билгеләнгән бюджет хисаплылыгын төзү, тапшыру һәм раслау тәртибенә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264.1 статьясындагы 5 пункты нигезендә кабул ителгән ведомство (эчке) актларына туры килүен раслау;

3) финанс менеджментының сыйфатын күтәрү.

3. Эчке финанс аудиты структур бүлекчәләр тарафыннан функциональ бәйсезлек принцибы нигезендә яки эчке финанс аудитының федераль стандартларында каралган очракларда, бюджет акчаларының баш администраторы, бюджет акчалары администраторының эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр бирелгән вәкаләтле вазыйфаи затлары (хезмәткәрләре) тарафыннан, ә әлеге статьяда каралган вәкаләтләрне тапшыру очракларында – структур бүлекчәләр яисә күрсәтелгән вәкаләтләр тапшырыла торган бюджет акчаларының баш администраторының (бюджет акчаларының администраторы) вәкаләтле вазыйфаи затлары (хезмәткәрләр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Бюджет акчалары администраторы үзе аның карамагында булган бюджет акчаларының баш администраторына яисә бюджет акчаларының әлеге баш администраторы карамагында булган башка администраторга эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру вәкаләтләрен эчке финанс аудитының федераль стандартлары нигезендә тапшырырга хокуклы.

Бюджет вәкаләтләрен үтәү сыйфатын, шулай ук активлар белән идарә итү сыйфатын, дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алу сыйфатын мониторинглауны үз эченә алган финанс менеджменты сыйфаты мониторингы үткәрелә:

1) тиешле бюджет акчаларының баш администраторларына карата билгеләнгән тәртиптә финанс органы (бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы) тарафыннан;

2) бюджет акчаларының баш администраторы тарафыннан үзенә буйсынган бюджет акчалары администраторларына карата үзе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә.

6. Финанс менеджменты сыйфаты мониторингын үткәрү тәртибе шул исәптән түбәндәгеләрне билгели:

1) финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечләрен исәпләү һәм анализлау, күрсәтелгән мониторингны уздыру өчен кирәкле мәгълүматны формалаштыру һәм тапшыру кагыйдәләре;

2) финанс менеджменты сыйфаты мониторингы нәтиҗәләре турында хисап формалаштыру һәм тапшыру кагыйдәләре.

7. Тиешле бюджет акчаларының баш администраторы финанс органы (бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы) каравына үзенә буйсынган бюджет акчалары администраторларына карата финанс менеджменты сыйфаты мониторингын үткәрү вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдим кертергә һәм финанс органы (бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы) белән килешенеп, әлеге финанс органына (бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органына) күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшырырга хокуклы.